**Россиянең иң яхшы санаторийлары 100легенә Татарстаннан “Бакирово”, “Шифалы су-Ижминводы” һәм “Радуга” кергән.** Беренче өчлек былтыргыча: “РЖД-Здоровье” санаторийлар группасы, Краснодар краендагы “Заполярье”, Башкортостандагы “Янган-Тау”. Санаторийлар елданел популярлаша. Хәзер Россиядә 1 740 санаторий эшли.

**Транспорт министры Фәрит Хәнифов әйтүенчә, 2024 нче елда Казан юлларын төзекләндерүгә 1,09 млрд сум тотылган.** Казаныбыз яз, җәй, көз буена БРИКС саммитына әзерләнде. Шәһәр юллары ремонты вакытында “бөке”ләр шактый булса да, нәтиҗәсе һәркемне шатландырырлык.

**РЖД берләшмәсеннән яхшы хәбәр – декабрь аеннан башлап Уфа-Мәскәү тиз йөрешле поезды җибәреләчәк.** №49/50 номерлы барлык уңайлылыклары булган әлеге поезд көн аралаш йөриячәк, Уфадан иртән чыгып китеп, икенче көнне иртән Мәскәүдә булачак. Бөгелмә, Нурлат, Димитровград, Ульяновски, Рузаевка, Рязаньда тукталышлары бар.


16+ *Безнең ил – үзе бер зур авыл*

# БЕЗНЕҢ АВЫЛ гыйдрәте

2024 ел, октябрь, №4 (124)

Почтада язылу индексы П2248















## Син дип күз нурымны түктем...

***Үткән тормышымны уйлый башласам, кинодагыча кебек күз алдыма килеп баса. Үз-үземә шаккатам – чыдаса да чыдый икән бу адәм баласы дим! Башымнан узган хәлләр әллә минем белән булмадымы соң ул дип тә уйлап куям. Ә чынлыкта, барысы да үзем кичергән, үземнең башлар күргәннәр.***

Егетем белән өч ел йөреп, бик яратып кияүгә чыктым. Бер-беребезне яхшы беләбез дип уйлый идем ул чагында. Ул елларда мин тулай торакта яши идем. Без йөргән шул өч елда эчендә егетемнең тулай торакка килми калган көнен хәтерләмим.

Егетем механик булып эшләде, бик оста иде ул. Машина төзәтәсе булса, аның янына гына киләләр иде. Кай төшендә проблема барлыгын тавышыннан ук белә иде. Төзелеш сорауларында да бар нәрсәне аңлый, слесарканы

**(Дәвамы 2 нче биттә)**

Экватор кадәр озынлыктагы (**40 075 КИЛОМЕТР**) пәрәвезнең авырлыгы нибарысы **340 ГРАММ**.

*Сиңа, дустым, бу сүз ахыргы сүзем:*
*Үзеңне сөй! Ярат үзеңне-үзең.*

**Габдулла ТУКАЙ.**

(Дәвамы. Башы 1 нче биттә)

да белә иде. Шуның өстенә бик чибәр дә иде! Мин үзем дә төшеп калганнардан булмадым, тегүче идем. Мин теккән әйберләрне җир өстенә җәеп салсаң, Мәскәүдән дә ары китәр иде!

Кияүгә чыгып, беренче кызымны таптым. Тормыш булгач, бөтен нәрсә кирәк: тегесен дә аласы бар, монысын да көйләп куясы бар, көндәлек чыгымнар да баштан ашкан! Минем әти-әниләр бик булыштылар. Сугым суйганда безгә һәрвакыт өлеш чыгаралар иде. Ел саен бәрәңге дә төяп киттек. Иремнең ярдәм итәрлек кешесе булмады. Беренче елларда аның тулай торак бүлмәсендә яшәдек. Мин арып-талуның ни икәнен дә белмичә, туктаусыз тектем дә тектем! Теккән әйберләрне авылга төяп алып кайта идем. Авылыбызның бөтен баласы мин теккән киемне киеп үсте. Пәлтә дисеңме, пәлтәгә пар иттереп шапка дисеңме, куртка – барысын да тектем! Күлмәк-итәк, кәчтүм-чалбарларны әйткән дә юк – аларны бер утыруда күзне йомып тегеп ата идем. Элек кибеттә берни дә юк иде бит. И-и, рәхәтләнде инде халык миннән тектереп, бик уңдылар миннән! Күрше авыллар да кызыгып киләләр иде, аларга да тегә идем. Бәяне дә артык куймадым, шуңа кешеләр минем кулны яраттылар.

Тора-бара, бер генә бүлмәле булса да, квартиралы булдык. Шатлыгыбыз чиктән ашты! Кызым беренче класска укырга кергәч, икенче кызымны таптым. Икенче баламны табарга уйламаган да идем. Кабаттан тегү тегеп чиләнәсем килмәгәндер инде. Ләкин ирем кистереп әйтте, табасың диде. Икенче бала булса, зуррак квартира сорарга да булачак иде шул. Олы кызыбызга иптәшкә бертуганы кирәк дип, икенче баламны табарга булдым.

Ә иремнең планнары башкача булган икән. Икенче кызымны табу белән, ирем читкә йөри башлады. Баштарак сиздермәскә тырышып йөрсә, вакытлар үтү белән атналар буе кайтмый башлады. Балалар әтиләрен юксына, аларга ни дип тә әйтә алмыйм, әтиегез эштә, соңрак кайтачак дип әйтә идем. Шулай көтә-көтә көннәр, атналар уза иде. Аннары ирем берни булмагандай кайтып керә дә, берни булмагандай сөйләшеп утыра, балалар белән уйный. Мин дә артыгын сораштырмадым. Ачы дөреслекне ишетүдән курыкканмындыр инде. Шуңа туры бәреп сораганым булмады.

Ләкин билгесезлектә мәңге яши алмыйсың бит, бу мөмкин дә түгел. Көннәрдән бер көнне өйдә телефон шалтырады. Бер хатын: “Сезнең ирегез ике елдан артык читкә йөри бит! Шуны да күрмисез”, – диде. “Алдашма, ышанмыйм”, – дидем. Шуннан ул бер адрес әйтте, хәзер ирең шунда, диде. Шул адресны эзләп киттем. Ахыргача бу сүзгә ышанмадым, нахак ягалар дидем. Адрес буенча барып кергәнчегә кадәр иремә ышанычымны югалтмадым. Булмас андый хәл дидем. Өйләнешкәнче үк мин аңа, күз нурларымны түгеп, күпме чалбар тектем, куртка тектем бит! Шуның кадәр яхшылыкларны онытырга мөмкин микәнни дип уйладым.

Тик ышанычым юкка булды. Адресны таптым, кердем. Ишек төбендә бүреге белән шарфы эленеп тора, ә ирем үзе түрдәге бүлмәдә йоклап ята иде! Мин коелып төштем, күз яшемне түгә-түгә, кая йөгергәнне дә белмичә, чаптым да чаптым... Бу вакытта үләселәрем килде, ике балам турындагы уйларым гына тотып калды мине. Өйгә ничек кайтып җиткәнемне, караватка ничек кереп егылганымны бөтенләй белмим.

Ярты сәгатьтән соң ирем кайтып керде. Яныма килеп басты да, яңагыма бик каты итеп сугып җибәрде! “Сук, әйдә, сук! Үтер!” – дидем. Ул мизгелдә иремә карата бары тик нәфрәт кенә иде, бүтән бернинди хис тә булмады. Шуны сизепме, ул каршыма тезләнеп: “Гафу ит, башка кабатламыйм”, – дип ялына башлады.

Хатын-кыз гел яхшыга гына өметләнә бит инде. Мин дә яхшыга өметләндем, бу авыр чорлар узып китәр, элеккечә чөкердәшеп яшәүне дәвам итәрбез дип уйладым. Ул елый, мин елыйм. Шулай кара-каршы утырып елаштык, сөйләштек, аңлаштык. Бик озак утырдык, төне буе сөйләшеп, башлар шаулады. Мин үз-үземне кулга алырга тырыштым, тынычлангандай иттем. Антлар бирдерттем. “Ул хатын янына бүтән бармыйм дип сүз бир! Шул чакта бу теманы бүтән беркайчан да кузгатмаячакбыз”, – дидем. Тезләнә-тезләнә сүз бирде. Тынычланыштык, үпкәмне йотып, алга карап яшәргә кирәк дигән фикергә килдем.

Ләкин минем өметләр акланмады. Койрыгын кысып, өйдә өч кенә көн торды ул. Ир-атларга шуны әйтәсем килә: минемчә, хыянәтне бик көчле хатыннар гына гафу итә ала. Анда да болай гына түгел, ә ир-ат акчалата тәэмин итә алса гына. Мин үзем дә акчаны яхшы таптым – бертуктаусыз тегү тектем. Ә ирем, чит хатыннар төяп, мин алган машинада чапты. Ул елларда машинаны да сирәкләр генә ала алды бит. Кирәкле кешеләргә мең сум взятка төртеп, шулай машина алып бирдем бит мин иремә.

Бер килсә, килә бит ул – ирем авариягә очрады! Янында утырып барган кешесе авария булган җирдә үк үлде. Ул чагында иремне юатыр өчен ни генә эшләмәдем! Ул көннәрне искә төшерсәм, әле дә сискәнеп китәм. Судны калтырый-калтырый көттек. Көне якынлашкан саен, менә утырталар, менә утырталар дип котым алынып торды. Юк, утыртмадылар аны.

Тагын бергә яшәп киттек. Ләкин бу яшәү – яшәү түгел иде инде. Күпме хәсрәтләр китерде ул миңа! Иремә елый-елый әйттем: “Мин синең чын хатының, син миннән әйбәтрәкне көндез шәм яндырып эзләсәң дә, таба алмассың. Хәзер бүтәнне эзләмә инде”, – дидем.

Ирем басылгандай булды. Ул вакытта аңа да җиңел булмагандыр – бергә яшибез, аерым йоклыйбыз. Мин балалар янында ятам, ә ул кухняда ята. Ирләр чыдый аламыни соң ул, беркөнне яныма килде дә, бергә ятыйк диде. Мин каршы килдем. Мин сине гафу итмәдем әле, минем ышанычымны яула дидем. Шул сүземә каршы ул минем төнге күлмәкне сыдырып кына төшерде. Өч көн рәттән шулай кабатланды.

Ахыры ни булып беттеме? Үлеме белән бетте... Ирем сентябрь аенда чит хатын белән урманга кереп, икәүләшеп машина эчендә газга тончыгып үлделәр. Гыйбрәтнең гыйбрәте булды бу. Бу хәлне аның туганнары да белми, минем туганнар да белми, балалар да белми, үзебезнең дом кешеләре дә белми.

Өстемнән йөреп, иремнең шулай ямьсез итеп китеп барганына да егерме ел үтте инде хәзер. Мин аны шушы егерме ел буена берничек тә гафу итә алмадым! Балаларны үзем генә үстереп бетердем, менә кечкенә кыз кияүгә чыкты, бала тапты. Алар Мәскәүдә торалар. Оныгымны роддомнан алып чыкканда йөзен кияүгә охшатып сөйдем. Сабыйга яшь ярым тулгач, минем яныма Казанга кунакка кайттылар. Егылып китә яздым – оник нәкъ бабасы! Билгеле инде, оныкны яратмыйча мөмкин түгел. Иремне бәхилләү юлын Ходай миңа шушы бала аркылы биргәндер иде...

**АЛСУ С. Казан.**

*Гөлназ белән без институт елларыннан ук таныш. Укырга кергәч, тулай торакта бер бүлмәгә урнаштырганнар иде, шуннан бирле аерылганыбыз юк диярлек. 5 ел буе бергә яшәдек, берберебезгә авылларга кунакка кайттык, бергәләп укыдык, ашарга пешердек, театрларга йөрдек.*

# ҮЗ ТОРМЫШЫ – ҮЗ ЮЛЫ



Институтны тәмамлагач, мин озак та тормый кияүгә чыктым. Егетем белән 5 курста укыганда таныштык. 5 курс – бик тыгыз чор бит ул. Диплом да язарга, башка имтиханнарга да әзерләнергә кирәк. Ә шулай да яшьлек дигәнең барысына да җитештерә икән. Укудан калган вакытларда Илмирга да вакыт таптым, кичкә кадәр урам әйләнеп керә идек.

Илмир Актаныш егете, мин Әлмәттән. Кайтып урнаша калсаң, аның ягында да, минекендә дә эш табарлык иде. Әмма безнең шушында, ияләшкән Чаллыда гына каласы килде. Чаллы – яшьләр шәһәре бит инде. Монда, ни дисәң дә, күңеллерәк. Кая булса бара башласаң да уңайлы, бөтен җирен беләбез.

Безнең әлегә үз фатирыбыз юк, акча түләп кешенекендә яшибез. Өйләнешүебезгә 3 ел, яшь ярымлык кызыбыз үсеп килә. Туй фотоларыбыз әле дә матур рамкалар эчендә өебезнең яме булып торалар. Мин аларга көненә әллә ничә карыйм. Минем яктан шаһит булып, әлбәттә инде, Гөлназ барды. Кияүгә чыккач ул кадәр еш күрешеп булмый. Әмма без көн саен диярлек шалтыратышып торабыз, безнең кызыбызга күчтәнәчләр алып, бәйрәмнәрдә ул кунакка килә. Мин аны иң кадерле кунагым итеп, тәмле бәлешемне салып, көтеп алам. Гөлназ да, укуын тәмамлагач үзләренә кайтмыйча, монда калды. Әлегә кияүгә чыкмады, әмма бер ел элек йөрешкән егете бергә яши башлады. Әниләре бик риза булмады инде, әмма нишләтәсең, үзләре шулай хәл иткәч, каршы да бара алмадылар. Гөлназның үзенә дә бик ошап бетми мондый мөнәсәбәтләр, әмма ул да басымчалык итә алмый. Егете белән без дә таныш, миңа ошады ул. Гөлназны ярата сыман күренә, Гөлназ да бик ярата аны. Мин аларның тизрәк өйләнешүен, аның да бәбәй мәшәкатенә чумуын телим. Бергә-бергә үстерер идек, балаларыбыз да безнең кебек дус булырлар иде дип хыялланабыз үзебезчә.

Кечкенә бала булгач, миңа көненә әллә ничә тапкыр урамга чыгарга туры килә. Җәяүләп кенә әллә кайларга кадәр барып җитәбез кызым белән. Парклар күп бит, барысында да күңелле. Күбесендә чәчәктән матур сыннар ясадылар. Күптән түгел шушы паркларның берсендә Гөлназның егете Алмазны күреп алдым. Без кызым белән мәш килеп күгәрченнәр куып йөрибез. Бала-чага күп җыелган урында кайнашабыз. Ә бу түрдәрәк, тынычрак урында утыргычта утыра. Үзе генә түгел, янында бер кыз да бар. Гөлназ белән һич бутап булмый, чөнки минем дустым кыска кара чәчле, ә моныкы сапсары итеп буялган, озын. Карадым да каттым боларга. Таныш-белеш очрамый тормый инде ул, мин аңлыйм. Әмма болар бит танышлар яисә дуслар кебек түгел, ә бер-берсенә гашыйк егет белән кыз төсле утыралар! Икесенә бер баллы мамык ашыйлар, бер-берсенә якын ук килеп утырганнар, Алмаз кызның җилкәсенә кулын куйган, ара-тирә мамыкны кызның авызына үзе каптыра. Кайсы дустың белән шулайлар килеп утырасың инде, юк бит! Кызга да ошый булса кирәк, елмая, чырык-чырык көлә.

Бер-беребездән ерак торгач мин аларның ни сөйләшкәнен ишетмим. Алар мине күрмиләр. Алар, гомумән, беркемне күрмиләр. Әйтерсең, паркта икесе генә, бүтән беркем дә юк. Без кызым белән шактый тордык әле анда. Ул арада Алмазлар торып китеп бардылар. Паркның икенче ишегеннән кочаклашып чыгып киттеләр. Минем якка килсәләр дә яшеренмәс идем. Әмма артларыннан бармадым инде, кычкырып дәшмәдем дә. Калган көнем – көн булмады.



Юл буе, кич буе уйланып йөрдем. Нишләргә? Гөлназга әйтергәме, юкмы? Бергә яшиләр, ләбаса. Фатирга бүлешеп түлиләр. Соңгы күрешүебездә дә, телефоннан сөйләшкәндә дә Гөлназда аны-моны сизмәдем. Димәк, Алмазның хыянәте турында берни белми. Бу турыда мин хәтта иремә дә сөйли алмыйм. Беләм бит ни әйтәсен, кысылма, синең эш түгел, үзләре беләләрдер, диячәк. Әмма мин алай җиңел уйлый алмыйм! Иң якын дустым бит ул! Аның бит бөтен өмете шушы Алмазда! Күреп тә әйтми калсам, мин шушы егет төсле ялганчы булачакмын килеп чыга. Әйтсәм, араларына керәм, талаштырам дигән сүз. Кем белгән бит ул Алмазны, бәлки Гөлназны чынлап яратадыр да, ә бусы белән болай гына йөридер? Бәлки киләчәктә ул Гөлназга менә дигән ир булыр? Кайбер ирләр шундый бит, үзләре читкә йөриләр, ә хатыннары берни белми, сизми. Кем әйтмешли, бүре дә тук, сарыклар да исән. Күргәннәремне сөйләп, мин аларның киләчәген җимерермен бәлки? Ә бәлки киресенчә, дустымны киләчәктә булачак зур хыянәттән саклап калырмын? Хәзер бит әле ул егетенә беркем түгел, уйлап карасаң. Ә хатын булгач, балалар тугач сөйгәненеңнең хыянәт ачысы әллә ничә тапкырга авыррак булачак. Шул ук вакытта, Гөлназның күзенә ак-кара күренми торган вакыт хәзер. Әйтсәм дә, ничек кабул итә әле ул? Әллә миңа ышанмас, үпкәләр, гаепләр – белмәссең бит. Көн артыннан көннәр уза да уза, ә мине намус борчый, корт кебек эчтән кимерә. Вакыт бара. Бәлкем вакыт белән бу борчулар да югалыр, барысы да әйбәт булыр.

**ЛАНДЫШ, Уфа.**

ГЫЙБРӘТХАНӘ



# ЯМАН СҮЗ

***Балалары үсеп, инде тормышлары көйләнеп кенә җитте дигәндә, Нәҗиягә әлләни булды. Бер чирдән терелде, икенчесе аягынннан екты. Тутырган тавык кебек түмтүгәрәк гәүдәсе ике-өч ай эчендә ябыгып, зур яшел күзләре эчкә батты. Кайчандыр сыланып торган киемнәре карачкыга эленгән чүпрәккә охшап калды.***

## ҮЛЕМГӘ ЯСАГАННАР...

Бер табибтан икенчесенә футбол тубы кебек типкәләп озак йөрттеләр аны. Нинди диагноз куярга белми йөдәделәр. Табиблар язган уколларны алып, даруларны эчеп тә хәле яхшырмады хатынның. Туганнары, гаиләсе Нәҗияне терелтү юлларын эзләде, танышлары арасында күрәзәчегә барып карарга киңәш итүчеләр дә аз булмады. Күрәзәчегә барма, башыңа хәсрәт алма дип әйтүчеләр дә табылды. Башта ул моңа көлеп кенә карады, бөтен ышанычы табибларда иде. Тора-бара аларның кеше язмышына битарафлыгы Нәҗиянең җанын елатты, нервылары какшап, күзләреннән яшьләре чыкмас, авызына төкереге килмәс булды. Көннән-көн хәлсезләнә барган, әле пенсия яшенә дә җитмәгән хатынның башында төрле уйлар кайнады. Шушындый матур гаиләсе, дуслары, хезмәттәшләре булганда, аларны ташлап якты дөньядан бер дә китәсе килми иде.

Тәмам бетәшкән Нәҗияне язмыш барыбер күрәзәче ишеген шакырга мәҗбүр итте. Күрәзәче, аңа бер текәлеп карады да, нигә килгәнен дә сорамыйча:

– Сине бозганнар, үлемгә ясаганнар, – диде.

Нәҗия, бу сүзләрне ишеткәч, аптырап китте. Үзенең дошманнары да булырга мөмкинлеге моңа кадәр башына да килеп карамаган иде аның. Ул, көчкә телен әйләндереп:

– Кем? – дип кенә сорый алды.

– Туганыңның аерылган хатыны яки якын дустың. Үзеңә озак ачу саклаган, үчен шулай алырга уйлаган. Ярый вакытында килгәнсең, берәр айдан инде ярдәм итеп тә булмас иде үзеңә, – диде.

Нәҗия ни әйтергә белмәде, йөзе чытылды:

– И, Ходаем, миңа үлем теләрлек кемне рәнҗеттем икән? Бер генә дә хәтерләмим бит, – диде ул, ачынып.

– Исеңә төшер, – диде күрәзәче. – Бәлки, синең аркаңда кемдер бәхетсезлеккә юлыккандыр?

Нәҗия ишле гаиләдән булганга, күңеле аша бер-бер артлы туганнарын барлады. Сәлим гаиләсе белән яши. Хәлим ике тапкыр өйләнде, Җәлил – өч, ә вакытлыча яшәгән хатыннары?.. Юк, ул тиз генә җавап таба алмас. Дулкынланудан Нәҗиянең иреннәре дерелдәде, күзләре кызарды, тик елый алмый иде ул.

Хатынның хәлен сизенде күрәзәче:

– Ул хәтле кайгырма, уйларга вакытын бар әле, – диде.

– Аннан ничек котылырга була соң? – дип сорады Нажия, кипкән телен көчкә әйләндереп.

Күрәзәчедән күзләрен алмыйча, сумкасыннан шешә алып, берничә йотым су эчте.

– Бозымны үзенә кайтарсак кына!

– Ә кайтармасак?..

– Мин синең белән уен уйнамыйм. Кайтармасак, озак яшәмәссең.

Нәҗиянең куллары гына түгел, бөтен гәүдәсе калтырый башлады. Ул уйларга тиеш! Ялгышып, гомерлек җан җәрәхәте аласы килми аның. Тик яшисе килү теләге тагын да көчлерәк. Балаларны гаиләле итәсе, булачак оныкларын кулларына алып сөясе килә бит әле.

– Уйларга вакыт кирәк миңа. Кеше тормышы бит ул. – диде Нәҗия. – Иртәгә килсәм буламы?

– Үзегезгә карагыз! Хушыгыз, соңга гына калмагыз, – дип озатты аны күрәзәче хатын.

## ЯШИСЕМ КИЛӘ!

Икенче көнне дә, өченчесендә дә бармады, һаман уйланды Нәҗия. Беркемгә дә начарлык эшләмәгәнлегенә, андый уйларның башына да килмәгәненә ышана иде хатын. Яшисе килү теләге барын да җиңде.

Күрәзәче күптәнге танышы кебек каршы алды:

– Киләсеңне белдем. Вакытның синең файдага бармавын аңлагансыңдыр. Үзенә кайтарабызмы? Әллә?.. – диде күрәзәче.

Тәвәккәлләп килгән Нәҗиянең күңелен кабат шик корты кимерә башлады, дулкынланудан йөзе кызарды.

– Биредә өченче җавап юк. Йә син, йә ул!

Күрәзәченең йөзе кырыс, сүзләре катгый иде.

– Яшисем килә! – диде Нәҗия, күзләрен идәнгә төбәп.

– Әйдә, утыр! Күзләреңне йом. Үзеңне сәламәт, бәхетле кеше итеп күз алдыңа китер.

Нәҗиянең колагына вакыт-вакыт күрәзәченең нидер пышылдавы гына ишетелгәләп алды. Беренче урынга аның сәламәтлеге, бәхетле тормышы куелган иде.

Күрәзәчедән чыккач, бик нык аруын тойды Нәҗия, көчкә генә өйләренә кайтып җитте. Ул кичне йокларга көндәгедән иртәрәк ятты. Төшендә үз гәүдәсенең ап-ак күлмәктән кабер өстенә күтәрелүен күрде. Шулвакыт колагына берничә ел элек гүр иясе булган әнкәсенең:

– Иртә әле сиңа, кызым, – дигән ягымлы тавышы ишетелде.

Шуннан Нәҗиянең сәламәтлеге күзгә күренеп яхшыра башлады. Тамагыннан аш үткәч, бит очлары алланып, күзләрендә нур кабынды. Тормышлары кабат ямьләнеп, инде киләсе көннәргә яңа планнар корып йөргән көннәрнең берсендә, балачак дусты Гөлсәриянең үлү хәбәрен ишетү Нәҗиянең күңел тынычлыгын качырды. "Әллә чынлап та күрәзәче әйткәннәр дөрескә чыктымы? Булмас! Гөлсәрияме? Ни өчен?" – дигән сораулар болай да авырткан башын тирән уй коесына, хатирәләргә чумарга мәҗбүр итте.

Кеше дигәнең бигрәк катлаулы зат, бергәләп бер пот тоз ашау да җитми икән бит. Бергә уйнап үстеләр, бер сыйныфта укыдылар, балачак хыялларына кадәр уртак иде. Җитмәсә, гаиләләрен дә бер елны корып, матур итеп туйлар уздырдылар. Гөлсәриянең Рафисы Нәҗияләргә, чыбык очы булса да, туган тиешле. Юк, булмас! Гөлсәрия ни өчен дустына ачу сакларга тиеш? Яшьрәк чакта гаиләләре белән бер-берсенә кунакка йөрештеләр. Еш зарлана иде дусты Рафистан. Әйе, бервакыт Гөлсәрия иреннән бик зарлангач әйтте шул, фәкать хатынның үзен җәлләп әйтте:

– Шулкадәр начар булгач, торма соң, кит! Табылыр әле яхшырак кеше, – диде.

Каты итеп әйтте, Гөлсәрия сискәнеп куйды хәтта. Ләкин Рафисны ташлыйсы килми иде аның, гаиләдә аралар җайланасына чын күңелдән ышанды. Еш елый иде Гөлсәрия. Ә Нәҗия очрашкан саен шул бер сүзен кабатлады: "Аерыл, түзеп торма!"

Чынлап та, Гөлсәрия берничә ел шулай яшәде дә, Нәҗиянең сүзен тыңлап, аерылды, бертуган апасы янына Мәскәүгә китеп барды.

## БӘХЕТЕМ ЧИТТӘН УЗДЫ...

Шуннан соң ике дус арасы ничектер суынды сыман, Нәҗиянең Гөлсәрия белән аралашырга мөмкинлеге булмады. Кайвакыт имеш-мимешләр генә килеп җиткәләде Нәҗия колагына: "Кияүгә чыккан икән, кыз бала үстерә", – диделәр. Бу хәлләрдән соң Рафис хәтәр эчә башлаган дигән хәбәр дә килеп ирешкән иде колагына. Хәзер Нәҗия ул елларны ачык кына искә дә төшерә алмый инде. Ул чаклы җентекләп төпченмәде ул, күңеленнән дустының яңадан тормышка чыгуын хуплады гына. Аның уенча, чибәр, яшь хатын гомерен заяга уздырырга тиеш түгел. Тормышка чыккан вакытта Гөлсәриянең тел төбендә һаман бер сүз – тизрәк бала табасы килү иде шул. Ләкин Рафис белән ул бәхетне татырга җитешмичә калдылар. Хатын-кызның бар бәхете дә ана булуда ләбаса. Аннан, күпмедер вакыт узгач, бер сыйныфташы очрап,



Гөлсәриянең язмышы турында тагын яңалыклар өстәде. Икенче гаиләдән дә бәхете булмаган Гөлсәриянең. Беренче ире Рафис янына кабат кайткан ул, тик эчүеннән туктаган ир икенче гаилә корырга өлгергән булган инде.

Тагын уйланды Нәҗия. Әллә чынлап та Гөлсәрия бозым эшләүгә барган?! Ни сәбәпле, ни өчен?! Балачак дустына игътибарсызлыгы, хәбәрләшми яшәве өчен үпкәләдеме? Юктыр, шуның өчен генә иң явыз дошманыңа да теләмәслек гамәлләр кылып булмый. Берничә ел элек Гөлсәриянең шәһәргә кайтып урнашуы турында ишетте ул. Нигәдер дусты килмәде аларга, юкса бер үк урамда яшиләр. Ә Нәҗия, кайчак аны исенә төшерсә дә, төгәл генә кайда яшәвен белмәгәч, эзләп йөрмәде. Бәлки, Гөлсәрия үзен бәхетсез дип санагандыр? Бәхетсезлеген Нәҗиядән күргәндер? Ә бала? Гөлсәрия бит үзе бала дип саташты. Әнә кызы инде гаилә корырга да өлгергән булган. Хатын-кыз өчен бу бәхет түгелмени? Шулвакыт колагына Гөлсәриянең үпкәле тавышы ишетелгәндәй булды: "Рафистан китәргә син котырттың, бәхетсез иттең. Гөнаһыңны таны, Нәҗия-я-ү!"

**ИСХАКОВА Г., Татарстан.**

***Танышларның кияүгә чыкмаган кызлары бар. Былтыр кырык яше тулды инде, ә йөргән кешесе юк. Югыйсә, төскә-биткә дә күркәм, холкы да тыныч. Әти-әнисенең бердәнбер мәхәббәт җимешләре булып үсте ул, аны бик тырышып тәрбияләделәр.***

# АРТЫК ТӘРБИЯ

Бөтен булган акчалары шул кызга тотылды, мәктәптә укыганда йөрмәгән түгәрәге калмады. Бик тыңлаучан кыз булып үсеп җитте ул. Хәзер бер шифаханәдә шәфкать туташы булып эшли. Гомергә тыйнак бала булды, әти-әнисе шулай тәрбияләде, тыйнаклыкка өйрәттеләр. Әллә тыйнаклык таләпләрен арттырып җибәрделәрме – кызыбыз ялгыз калды. Егетләр белән танышырга каршы да түгел шикелле ул. Ләкин: "Миңа караган егет юк бит әле, апа", – дип уфтанып куя. Бәби дә табасы килә. Аны ашыгыч рәвештә кияүгә бирергә кирәклеген беләбез, тик үзенә тиң яр таба алмый, кеше аша да танышасы килми. Югыйсә, эше һаман кеше арасында, анда кемнәр генә килми дә, кемнәр белән генә сөйләшергә туры килми. Ә үзенә дигән кеше һаман юк!

Быел ныклап уйлана башлады. "Кияүгә чыгып булмаса, һичьюгы бәби табарга кирәк", – ди. Бик кызгандым шулай дигәч. Югыйсә, менә дигән кыз – үзе матур, үзе акыллы, үзе бөтен эшне булдыра. Үзе машина да йөртә, җебегән кыз түгел.

Яшьрәк чагында йөргән егетләре бар иде аның. Ләкин аңлашып бетә алмадылар. Кызны дөрес дип исәпләнгән тәрбия белән тәрбияләделәр бит – кияүгә саф кыз булып чыгарга тиешсең диделәр. Тормышта гел без теләгәнчә, без тәрбияләнгәнчә генә килеп чыкмаганын кабул итә алмый ул һәм бу аның гаебе түгел. Ул шул тәрбиядән тайпыла алмый. "Ничек инде ул алай, мин саф килеш кияүгә чыкмасам, дөрес булмаячак бит", – дип әйткәне дә бар иде. Теге егеләре басымчалык иткәннәрдер. Шуңа алар белән арасы өзелгәндер. Кызыбыз шул тәрбиясендә нык торды, һаман тора, берничек тә боза алмый. Ә яше бара бит. Мин аны гел уйлап йөрим инде. Ул үзе дә борчыла: "Каян табыйм соң, апа, каян табыйм? Мин егет эзләргә чыгып китә алмыйм бит инде. Миңа кияүгә чыгу язмагандыр ул", – ди.

Уйлап карасаң, артык дөреслек тә бәхетсез итә икән кешене. Озакламый бала табар вакыты да үтәчәк, мондый тормышның мәгънәсе нәрсәдә.

**СӘРИЯ М. Казан.**



***Романнардагы шикелле, безне Ринат белән Гөлгенә дип йөрттеләр. Мин гармунда уйный идем. Бергәләп бөтен бәйрәмнәрдә җырладык. Аннары гомерем буе Ринатны сагынып җырлармын дип, кем уйлаган? Кызганычка каршы, шулай килеп чыкты, чөнки без бергә була алмадык. Яшьлегемдәге мәхәббәтемне гомер буе йөрәгемдә саклыйм.***

# Мәңге мине көтеп тор

Бик матур йөрдек без, бөтен авылыбыз безгә сокланып карый иде. Өч ел очрашып йөрдек. Яратышуыбызны һәркем белде, бер-гә буласыбызга бер шик тә юк иде. Тик нидер булды, мин төгәл генә аңлый да алмый калдым. Беркөнне кич Ринат мине капка төбенә чакырып чыгарды да, күземә туп-туры карап: “Мин сине яратмыйм!” – дип әйтте. Минем тыным кысылды, ни еларга, ни көләргә, нидер әйтергә дә белмәдем. Торып чаптым, иптәш кызлар янына барып җиткәч кенә, үксеп еларга тотындым. Ни булды да, ни булды дип сорый башладылар. Мин барысын да әйттем, Ринат “яратмыйм” дип әйтте, дидем. Дөрес, мин аңа үпкәләдем, ләкин каргамадым! Эчемнән генә әйтеп куйган сүземне дә хәтерлим әле. “Мәңге мине көтеп тор!” – дидем.

Ринатның сүзләренә тиздән аңлатма да табылды – өйләренә килен төшерделәр. Без белгән-күргән кыз түгел, каяндыр ерак авылдан. Мин дә озак йөрмәдем, кулымны сорап килгән беренче кешегә кияүгә чыктым. Булачак иремдә бераз Ринат чалымнарын да тоемладым шикелле. Бер-ике ел үтте микән, Ринат мине эзләп килде: “Ялгышканмын, зинһар, китик бергә читкә чыгып, гомерем буе өзелеп сөярмен үзеңне”, – дип, елый-елый сорады. Мин ул чакта корсаклы идем инде. Ул сәбәпле генә дә түгел, гомумән, иремә беркайчан да хыянәт итмәячәгемне кистереп әйттем. “Син үзеңнең юлыңны сайладың, Ринат”, – дидем. Аннан соң ул ике-өч тапкыр өйләнеп карады, барысы да уңышсыз килеп чыкты. Яшьлектәге: “Гомерем буе сине генә яратачакмын!” – дигәне хак булып чыккандыр инде.

Яратмыйча кияүгә чыккач, без дә ирем белән ахыр чиктә аерылыштык, балалар үсеп чыгып киткән иде инде ул чакта. Иптәш хатыннар минем хакта Ринатка шундук җиткергәннәр дә, ул минем янга килде. Әнисе белән яши иде ул. Тормышны “чиста биттән” башлап карарга тәкъдим итте. Мин карышмадым инде, яшәп карарга булдык. Шулай итеп, күп еллар үткәч, барысы да арттa калгандыр дип уйлаганда, без аның белән яңадан табышып, бергә-бергә яши башладык. Яшьлек мәхәббәте күңелдә сакланып калса гына матур икән ул, ә яшьлек мәхәббәте белән олыгайгач кавышып яшәве гел икенче нәрсә икән. Кешенең бөтен тискәре яклары ачыла, яшьлектә күзгә күренмәгәннәре дә аермачык күренә. Ринатның да шундый яклары ачылды, бәлкем үзем дә үзгәргәнмендер инде. Күңел күзе дә башкачарак күрә башлагандыр. Ринатның эгоист, саранрак яклары теңкәмә тиде. Ләкин аннан гына яратуым кимемәде, барысын да гафу итеп яшәдем. Ринатның өйләрендә яшәдек, яныбызда – аның анасы. Ринат әнисенең итәгеннән аерыла алмады, аның сүзеннән чыкмады. Аларда яшәве бик авыр булды миңа. Ачыктан-ачык битәрләмәсә дә, анасы үзебезчә яшәргә ирек бирмәде. Шәһәргә китеп яшәргә сөйләшкән идек, әнисе җибәрмәде. Ә Ринат аның сүзеннән чыга алмады. Олы гына адәм бит инде, югыйсә, ә анасының сүзе – закон! Мине алдына утырты да, күз яшьләре белән: “Кадерлем, менә шулайрак бит әле – әни җибәрми, чыгып китсәң хәер-фатихам юк дип куркыта... Аның сүзен таптап чыгып китә алмыйм бит!” – диде.

Мин ике арада бәргәләндем-бәргәләндем дә, түзә алмыйча чыгып киттем ул читлектән. Ләкин ул чор минем күңелемдә бик матур булып сакланды – Ринат белән бергәләп бакчада эшли идек, бәрәңгеләр өя идек. Ул тыныч кеше, талашмый-нитми. Ләкин өйдә яшәмәслек атмосфера тудырылды. Безнең бергә чөкердәшеп бәрәңге өйгәнебезне дә тынычлап карап тора алмый иде анасы, көнләшүе булды микән. Арабызга килә дә кысыла иде. Ә Ринат шундый романтик – болында булсынмы, урмандамы – миңа чәчәкләр җыеп алып кайта, бергәләп җиләккә йөргәндә каен җиләкләреннән матур итеп букет ясап бирә. Анасы һәрвакыт ияреп йөрде һәм аркылы төшә торган иде.

Ринат ялгыз, аның белән хәзер дә телефоннан аралашып торабыз. Ул мине барыбер оныта алмады, сагына. Чөнки ярата, мин сизеп торам. Бүтән өйләнмәде дә. Менә шундый сәер тормыш: яратса да, бергә яшәү мөмкин түгел. Мин аның мәхәббәтен һәр сүзеннән тоемлап торам, ул икебез белән бәйле вакыйгаларны, көннәрне, елларны бөртегенә кадәр хәтерли. Миңа шалтырата да: “Исеңдәме, синең белән су буена барганда беренче мәртәбә күрешкән идек. Син анда иптәш кызларың белән идең, туктап сөйләшеп тордык әле. Аннары икенче көнне мин сине күрер өчен тагын шул сукмакта көтеп тордым сезне. Сез тагын үтеп киттегез. Бу юлы син мине күрмәдең дә шикелле, бер кыз белән нидер чыркылдаша идең”, – дип, шулкадәр яратып, кадерләп сөйли. Яратмаган кеше шул кадәресен исендә йөртмәс иде бит инде! Инде хәзер 40 елдан артык вакыт узган бит бу хәлләргә!

Кайчак авылга кайтканда, сирәк булса да күрешкәлибез. Хәзер икебез дә олы яшьтә булсак та, аның хисе нәкъ элеккечә. Әнисе нәкъ теге чакларда кебек басымчалык итеп тора, хәзер 90нан өстә инде ул, алай да җир җимертеп йөри әле. Ринат башын салып утыра да, уфылдап миңа әйтеп куя: “Менә уч тутырып акча эшлим, ә үземә сыра алырлык акчаны да әниемнән сорап алырга кирәк”. Анасына берничек тә каршы төшә алмый, шулай тәрбияләнгән. Чынлап та, оя корып яши дә алмады шул. Иң гаҗәбе шунда, мин аны хәзер дә яратам, бу хисне беркая да куеп булмый икән.

**Гөлгенә МИННУРОВНА, Әгерҗе.**

***“Штрафлар зур, чат саен камера, шуның өстенә таяк белән дә еш туктаталар” – дип еш зарлана ир-ат халкы. Ә мин законнарның шулай каты булуына сөенәм генә. Каты тотсыннар шоферларны, бәйдән ычкындырмасыннар! Әле шулай торып та, таманга гына туры килә.***



# ХАТЫННАР КАЛА

Безнең яшьлек совет чорына туры килде. Авылдан килдек тә, Казанга урнаштык ирем белән. Ул вакытта чыгып китеп урнашу, завод-фабрикаларда эшләү үзенә күрә мода иде бит. Икешәр смена эшләп, эт булып арыйбыз, борылырга да урыны булмаган тулай торакта яшибез. Ә шулай да, авылга кайтканда бездән дә дәрәҗәле кеше юк. Матур киемнәр киеп, әллә кем булып кайтып төшә идек. Мәктәптә үк шоферлыкка укып чыккан ирем Казанда руль артына утырды.

Хәзерге шоферлар бөтенләй бүтән. Элек шоферлар эчеп эшләделәр. Күбесен яхшы белә идем бит – арадан берсен генә булса да, ичмасам, эчми дип әйтеп булмый иде. Эштән соң көн дә эчәләр. Йә гаражда, йә шул ук машинада җыелышып утыралар. Аракы – шофер хатыннарының үзәгенә үткән әйбер иде. Бәйрәм көннәрендә генә дә түгел бит, көн саен. Ничек йөргәннәр алар юлда, иртән ничек утыртканнар диген үзләрен. Шаклар катам. Югыйсә, рейска чыгар алдыннан барысын да өрдереп карыйлар иде бит. Арада әләгүчеләр дә булгандыр инде, булмый калмагандыр. Әмма минем иремнең бер дә кире кайтып утырганы булмады.

Мактанып сөйләвем түгел, киресенчә, үзе исән булмаса да, хурланам шуның өчен. Аның эчүе аркасында начар яшәдек без. Шуның кадәр эшләп тә, акча җитми торган иде. Исереккә берни кирәкми бит, өстәп эчәргә тагын шешә, капкаларга булсын. Иртән башлана аннары: “Ни киим?”, “Бу пычрак чалбар белән чыгып китимме?” – ише гаепләүләр. Запас алып куярга кирәк инде ул, анысын яши башлаганда ук белә идем. Әмма запас өчен акча кирәк бит. Ә ир бөтен булганын эчеп барды. Миңа тормыш күтәргә дә, балаларны карарга да кирәк. Әй, аларны сөйләп торсаң тагын! Искә алсам, тагын нервы кайный башлый, тормышның шулай килеп чыкканына ачу килә.

Берсендә үз акчаларымны тоттырып чыгарып җибәрдем моны. “Бар, – мин әйтәм, – бер тавык алып кайт, шулпа пешерербез”, – дидем. Әле ул чакта кибетләрдә берни юк бит, бар да дефицит. Ә шоферларның барыбер танышбелешләре була, аларга астан гына сатып алу мөмкинчелеге бар иде. Менә шул тавыкка дигән акча башына җитте дә иремнең. Эчкече кешенең кулына акча керсә, тамак ягын, гаиләсен кайтыртамы инде ул? Чыгуга ук, үзе кебек берничә шешәдәш белән очрашып, бер гараж почмагына утырганнар. Сыйлаучы – минем ир ул көнне. Китүенә ике сәгатьләп үткәч, аңладым инде үземнең хатамны. Әмма соң шул, чыгып эзләп тапсам да, ул акчаларның юк икәне билгеле. Көзнең салкын көннәре төшкән иде инде ул вакытта. Җир туң иде, әмма кышка кермәгән идек әле. Гадәттә, ирем көндез юкка чыкса, никадәр исерек булса да, кичкә кайтып ава торган иде. Ә бу юлы кайтмый да кайтмый. Балалар мәктәптән кайтып инде дәресләрен хәзерләп бетерделәр, ә бу юк һаман. Эч поша инде барыбер, исерек булып йөрсә дә, борчыласың бит. Бер тәрәзәдән икенчесенә йөренәм – күренми бу. “Ник бу вакытка кадәр утыра инде, иртәгә таңнан торасы бар бит”, – дип уйлыйм әле эчтән генә, сменасы өчен борчылам. Көтеп-көтеп тә кайтмагач, өй тирәли генә булса да әйләнеп керергә булдым. Әлләни еракка китеп эзли алмыйм, чөнки караңгы бит, көз – куркыта да. Исерекләр багана яктысында утырмый бит алар, караңгы почмак эзлиләр. Бер-ике әйләндем дә, кереп киттем кире.

Төн уртасында үзе кайтып керде тагын, зерелдәп каткан бу, эчкән аракысы чыгып беткән диярлек. Менә шешәдәшләр диген син боларны! Минем ир хисабына эчкәннәр, ә берсе дә янында утырып калмаган. Барысы да өйләренә кайтып йоклаганнар. Ә минеке тора алмаган, эчкән урынында йоклап киткән. Салкын җир бит, эченә үткәч, уянган. Икенче көнне аягына да баса алмады – югары температура, каты ютәл. “Менә күрдеңме, аракың нишләтә?!” – мин әйтәм. Үзем сүгәм, үзем караватына кайнар чәй ташыйм. Терелтәм, янәсе, ике көн дигәндә рәтләп эшкә чыгарып җибәрәм.

Ләкин дөнья син дигәнчә генә бармый шул. Үземнең хәлдән килмәгәч, табибларга киттек, яткырдылар. Беренче анализлары ук күрсәтте инде – үпкәләренә салкын тигән, үзәгенә үткән. Температурасын төшерә алмадылар, ике ай дигәндә, китеп тә барды шулай, 40 яше дә тулмаган иде. Кызганыч та, түгел дә инде. Башы да юк түгел иде үзенең, эчмәгәндә нык әйбәт кеше иде, сөйләшеп туеп булмый торган иде. Аракы барысын тигез күрә шул: моның башы бар, бу юләр дип тормый – рәттән кыра. Без яшәгән баракта 8 гаиләнең алтысының ире шофер иде. Минем ирдән соң 5-6 ел эчендә үлеп беттеләр. Барысы да!

Бараклардан күченгәнебезгә шактый инде хәзер, 20 еллап бар. Ә шулай да, без хатыннар һаман да элемтәдә торабыз әле, шалтыратышабыз. Барыбызның да бер үк язмыш бит: ирләр авызларын йөгәнли алмаганга үлде, ә без калдык. Ярый инде, арадан икебез кабат кияүгә чыкты. Ә калганнарыбыз калдык япь-яшь көе ирсез, тормыш арбасын үзебез генә тартып. Шуңа әйтәм, ирләр күп эчмәсен, хатыннары белән озак яшәсеннәр, сәламәт булсыннар.

**ДИЛБӘР, Казан.**